КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 4 июль г.Казань № 544

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында 2007/2008 – 2017/2018 уку елларында Россия Федерациясенең халык хуҗалыгы оешмалары өчен идарә итүче кадрлар әзерләү буенча дәүләт планын тормышка ашыру турында» 2007 ел, 27 июнь, 253 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында 2007/2008 – 2017/2018 уку елларында Россия Федерациясенең халык хуҗалыгы оешмалары өчен идарә итүче кадрлар әзерләү буенча дәүләт планын тормышка ашыру турында» 2007 ел, 27 июнь, 253 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 12 октябрь, 556 нчы; 2008 ел, 15 декабрь, 887 нче; 2012 ел, 5 октябрь, 829 нчы; 2015 ел, 30 ноябрь, 905 нче; 2016 ел, 25 февраль, 114 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пунктта «Татарстан Республикасының икътисад министры М.Р.Сафиуллинга» сүзләрен «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган 2007/2008 – 2017/2018 уку елларында Татарстан Республикасында идарә итүче кадрлар әзерләү буенча дәүләт планы концепциясендә:

1 нче бүлекнең бишнче абзацында «Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән министрлыгы» сүзләрен «Россия Федерациясе Фән һәм югары белем бирү министрлыгының» сүзләренә алыштырырга;

3 нче бүлекнең утыз өченче абзацында «Программаны үтәүче буларак Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы» сүзләренә алыштырырга;

6 нчы бүлекнең икенче абзацында «2007 – 2010 елларда тиешле елга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы белән билгеләнә» сүзләрен «тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында 2007/2008 – 2017/2018 уку елларында Россия Федерациясенең халык хуҗалыгы оешмалары өчен идарә итүче кадрлар әзерләү буенча дәүләт планында:

беренче абзацта «һәм сәнәгать» сүзләрен төшереп калдырырга;

«Финанслар белән тәэмин итү» бүлегенең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль бюджет акчасы исәбеннән финанслау күләме тиешле финанс елына һәм план чорына федераль бюджет турындагы федераль закон белән билгеләнә»;

әлеге карар белән расланган Россия Федерациясенең халык хуҗалыгы оешмалары өчен идарә итүче кадрлар әзерләүне оештыру буенча Татарстан төбәк комиссиясе турындагы нигезләмәдә:

2 нче бүлектә:

икенче абзацта «Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы» сүзләренә алыштырырга;

дүртенче абзацта «Россия Федерациясенең Икътисадый үсеш һәм сәүдә министрлыгы» сүзләрен «Россия Федерациясенең Икътисадый үсеш министрлыгы» сүзләренә алыштырырга;

9 нчы бүлекне 8 нче бүлек дип санарга һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «8. Йомгаклау нигезләмәләре

8.1. Төбәк комиссиясе функцияләрне бу Нигезләмәгә таянып башкару өчен төбәк комиссиясе әгъзаларыннан, өченче затлардан төбәк комиссиясе компетенциясенә керә торган мәсьәләләрне тулы, һәрьяклап һәм объектив тикшерү өчен кирәкле күләмдә мәгълүмат сорарга хокуклы.

8.2. Төбәк комиссиясе әгъзалары, сорау җибәрелгән органнар яки вазыйфаи затлар соратып алына торган мәгълүматны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә кертә.

8.3. Төбәк комиссиясе мәсьәләне тулы һәм һәрьяклап тикшерү өчен экспертлар җәлеп итәргә хокуклы.

8.4. Төбәк комиссиясе эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8.5. Төбәк комиссиясе карарлары нигезендә чараларны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план

чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин